СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

26 апрель, 1997 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 46 (8058)

Бәясе билгеләнгәнчә

## Дәүләт Советы сессиясе

**24 апрельдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының XI пленар сессиясе эшли башлады.**

**Кайбер сайлау округларында Республика халык депутатларын сайлау йомгаклары турында Үзәк сайлау комисссиясе белдерүен тыңлаганнан соң, депутатлар Татарстанның Җир кодексы проектын, Татарстанның Дәүләт бурычы турындагы һәм кайбер башка Законнарны беренче һәм икенче укылышларда кабул иттеләр. Татарстан Республикасының «Нефть һәм газ турында»гы законы тулаем кабул ителде.**

**Сессиядә Татарстанда хезмәткә түләүнең минималь күләме турында Республика Премьер - министрының беренче урынбасары Р.Ф.Моратов чыгыш ясады һәм шул турыда Закон тулаем кабул ителде. Моннан ары Республикада хезмәткә түләүнең минималь күләме аена 350 мең сум булачак.**

**Сессия эшендә 22 майга кадәр тәнәфес игълан ителде.**

## Мөһим киңәшмә

**24 апрельдә Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев шәһәр һәм район хакимиятләре башлыклары, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрде.**

**Киңәшмәдә быелның беренче кварталында республиканың икътисадый - финанс хәленең йомгаклары каралды. Аерым алганда, финанс министрлыгының һәм салым инспекциясенең нәтиҗәле эшләгәнлеге, шуның нәтиҗәсе буларак беренче кварталда бюджетның керем өлеше үтәлүе һәм моның пенсияләрне, бюджеттагыларга хезмәт хакы түләүләрне яхшыртырга мөмкинлек бирүе билгеләп үтелде.**

**Бер үк вакытта Президент республиканың икътисадый һәм финанс хәлен ныгыту өчен күрелергә тиешле җитди чараларга, шул исәптән җитештерү өлкәсендәге бурычларга да, булганны бәрәкәтле тоту, акланмый торган чыгымнарны киметү, халыкны социаль яклау программасын гамәлгә ашыру юнәлешендә башкарылырга тиешле эшләргә дә җитди басым ясады.**

## РАЙОН ХАКИМИЯТЕНДӘ

Кичә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин авыл хуҗалыгы ассоциацияләре, промышленность, транспорт, төзелеш предприятиеләре һәм кайбер оешмалар җитәкчеләре белән көннең күп кенә актуаль мәсьәләләре буенча киңәшмә үткәрде. Ф.С.Сибагатуллин районның кайбер тармак җитәкчеләренең инвестицияләрне тарту мәсьәләсендә республика органнары белән үзара кирәгенчә актив эш итмәүләрен билгеләп үтәргә мәҗбүр булды, бу җөмләдән районга газлаштыру өчен 60 тонна торбаның һаман да кайтарылмавын мисал итеп китерде. Пенсия фондыннан кала күп кенә башка республика фондларының мөмкинлекләре начар файдаланыла, ә бит аларның средстволары социаль характердагы мәсьәләләрнең бер өлешен хәл итүне тизләтер иде. Автомобиль юллары төзү һәм ремонтлау эшләрен җәелдереп җибәрү зарурлыгына игътибар юнәлтеп, район башлыгы «Норлат» агрофирмасының гамәли эшчәнлеген яхшырту буенча конкрет тәкъдимнәр кертте.

Район «Сельхозтехника»сы республика хөкүмәте карары белән районның коммуналь милкенә тапшырылуын белдереп, Ф.С.Сибагатуллин агропромышленностьта реформа үткәрү мәсьәләләренә аерым игътибар юнәлтте, малларның продуктлылыгын күтәрү юнәлешендә тагын да тырышыбрак эшләргә чакырды. Анары төп басым язгы чәчүне үткәрү технологиясенә ясалды. Һәр хуҗалыкта механизаторларның эшен кичекмәстән ике сменада оештырырга кирәк. Туфракта дым каплау чараларын һич тә озакка сузарга ярамый. Язгы кыр эшләрен оешкан төстә, кыска срокларда һәм югары сыйфат белән үткәрү - көннең төп бурычы шул.

Киңәшмәнең икенче өлешендә Ф.С.Сибагатуллин Татарстан Дәүләт Советының XI нче пленар сессиясендә кабул ителгән карарлар һәм республика Президенты М.Ш.Шәймиев үткәргән киңәшмә йомгаклары белән таныштырды. Татарстанда хезмәткә түләүнең минималь күләме айга 350 мең сумга җиткерелде һәм бу башка социаль нормативларны да, аерым алганда балалары булган гаиләләргә айлык компенсацияләр күләмен яңадан карап чыгуны күздә тота. Ә бюджет средстволарының җитәрлек булмавы бюджет оешмалары структурасында кыскартулар зарурлыгы турында искәртә. Андый оешмалар җитәкчеләре бу хакта беренче чиратта уйланырга тиешләр.

Ахырдан Ф.С.Сибагатуллин Кизләү авылының 1000 еллыгы белән бәйле чараларны үткәрү буенча республика комиссиясе оештырылуы турында хәбәр итте.

Киңәшмәдә башка мөһим мәсьәләләр дә каралды.

## Маллар җәйләүләргә күчә

Муса Җәлил исемендәге КФХАндә җәй җәмәгать малларының барысын да лагерьларда асрау өчен күләмле хәзерлек эшләре башкарылды. Биналар төзәтелде, коймалар яңартылды, гомумән, осталар кулы тимәгән бер генә бина да калмады. Шуның нәтиҗәсе буларак, бүгенге көндә капланмаган дуңгызлар җәйге лагерьларга чыгарылды инде. Тагын 30лап ана дуңгыз өчен дә урын хәзерләнде.

Якын көннәрдә савым сыерлары, барлык мөгезле эре терлек тә җәйге урыннары - лагерьларга чыгарылачак. Сарыклар асралачак җәйләү дә маллар кабул итүгә тулысынча әзер.

## Районыбыз тормышыннан хәбәрләр

### Имтихан тоттылар

Атна уртасында СПТУ базасында район мәктәпләрендә авыл хуҗалыгы техникасын өйрәнүче үсмерләрдән имтихан кабул ителде. Егетләр юл йөрү, техник эксплуатацияләү кагыйдәләре буенча телдән имтихан тотсалар, берьюлы трактор йөртү күнекмәләрен дә күрсәттеләр. Компетентлы комиссия иртәгә авыл хуҗалыгы производствосында эшләячәк механизаторларның мәктәптә алган белемнәренең ныклыгын һәръяклап тикшерде. Имтихан тотучы 90 егетнең 60ы гына III класслы тракторчы таныклыгы алуы да шул хакта сөйли.

### Педагоглар белем өсти

Узган атнадан районда рус теле һәм әдәбияты укытучыларының белемен күтәрү максатында ике атналык курслар эшли башлады. Аны республика мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институты (ИТКРО) белгечләре - педагогия фәннәре кандидаты Г.Х.Әкбәрова һәм Т.О.Скиргайло алып баралар.

Курслар программасында теоретик, шулай ук практик занятиеләр үткәрү каралган.

Рус теле һәм әдәбияты укытучылары белән параллель рәвештә тарих укытучыларының белемен күтәрү курслары да оештырылган. Аларда 40лап педагог укый.

### Гала - концертка калдылар

« Татарстан - Минем Республикам» республика зона конкурсында лауреат исемен яулаган шәһәр балалар музыка мәктәбенең хатын - кызлар вокаль ансамбле бу көннәрдә конкурсның республика йомгаклау турын үтеп, гала - концертта чыгыш ясаячак. Коллективның иҗат тормышындагы уңышларның соңгысы булмас бу дип ышанасы килә.

**Хөрмәтле укучыларыбыз!** «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына икенче яртыеллыкка язылу бәясе дә элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калды. Район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.

*Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!*

## *Бүген - Тукай туган көн*



Габдулла Тукай - татар шигърияте күгендә янган якты йолдызларның иң зурысы. Ул калдырган иҗат мирасы һәм рухи яктылык - безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Аның исеме татар культурасының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәңгегә бәйле. Бөтен рухы, аһәңе белән халыкчан Тукай поэзиясе, үз заманында ук милли чикләрне үтеп чыгып, гомумкешелекнең азатлыкка омтылган иң изге идеалларын, хисләренең иң тирән серләрен югары гәүдәләндергән кабатланмас, уникаль бер шигъри дөньяга әверелде. Тукай шәхесенең, ул иҗат иткән рухи байлыкның еллар узган саен әһәмияте арта гына бара.

### Тукайга

Тормышыңда бәйрәмнәр аз булган -
Тартыш белән тулган көннәрең.
Шуңа, ахры, искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең...
Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп -
Халкың килде сиңа, мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән күтәреп.
Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне;
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең «Туган тел»еңне.
Буын арты буын алмашыныр,
Гасыр арты узар гасырлар.
Шигъриятең һәйкәленә шулай
Яшьләр һаман гөлләр ташырлар.
Халык моңы - синең моңың булды,
Халык күңеле - синең күңелең.
Ил гомере, халык гомере кебек
Озын булыр, шагыйрь, гомерең!

Шәүкәт ГАЛИЕВ

### Шагыйрь

*Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,*
*Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да,-*
*Күңелем минем яп - яшь калыр, һич картаймас;*
*Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.*

*Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!*
*Күтәрәм мин карт булсам да авыр тауны;*
*Күңелемдә көн һаман аяз - һаман да яз,*
*Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.*

*Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,*
*Утырмам тик, юк - бар теләк тели - тели;*
*Менмәмен мин, ходай кушса, мич башына,*
*Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.*

*Җырлый - җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;*
*«Без китәрбез, сез каласыз!»*
*- дип җырлармын,*
*Җәсәдәмне туфрак берлә күмгәндә дә.*

## Тукай бүләге лауреатлары

**Татарстан Республикасының дәүләт премияләре комитеты тәкъдимнәрен карап, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев 1997 ел өчен Габдулла Тукй исемендәге премияләрне**

«Г.Тукай»,»Дәрдмәнд»,«Б.Урманче» триптихы өчен рәссам **Абрак Әмир улы АБЗГИЛЬДИНга**,

Дж.Вердиның «Риголлетта» операсында Джильда, «Травиата» операсында Виолетта, Дж.Россининның «Севилья чәчтарашы» операсында Розина, Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партияләрен башкарган өчен М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һм балет академия театры солисты **Венера Әхәт кызы ГАНИЕВАга**,

«Хисемнең исеме» дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен шагыйрь **Ренат Мәгъсүм улы ХАРИСОВка (Ренат Хариска)** бирү турындагы Указга кул куйды.

# Авыл: Кичә. Бүген. Иртәгә.

## РАЙОН СОВЕТЫ СЕССИЯСЕ МӨНБӘРЕННӘН

**А.Савинов,**
**«Норлатшикәр заводы» АҖ генераль директоры:**

### Хуҗаларча эшлисе

Узган ел октябрьдә район хакимияте башлыгы карары белән «Восход» КХАсы «Норлат шикәр заводы» АҖнә ярдәмче хуҗалык итеп тапшырылды. Хуҗалыкның 2500 гектар үз җире бар иде, тагын «Чишмә» КХАсының 643 гектарын да куштылар. Без үзебезгә алганда хуҗалыкта 616 баш мөгезле эре терлек, 600 баш дуңгыз, 65 ат булып, бер сыердан көнлек савым уртача 3,5 килограмм иде.

Кышын төп игътибарны терлекчелек комплексында хәлне яхшыртуга һәм малларның баш санын саклап калуга юнәлттек. Хәзер көнлек савым 12,4 килограмм, мөгезле эре терлекләрнең тәүлеклек үсеше 637, шул исәптән мартта 717 граммга, дуңгызларныкы шул тәртиптә 357 һәм 406 граммга җитте. Быел 52 башка күбрәк бозау алынды. Аларны салкында асрау ысулын да кулландык. Анысын Биектау районында да карап кайттык. Аларда бозаулар да үлми, продукциянең үзкыйммәте дә бездәгедән түбән. Хәзер без дә бер симертү бүлеген шундый ысулга күчердек.

Ә менә дуңгызчылыкта хәл авыррак: мартта алынган үрчемне саклап кала алмадык. Хәзер моның сәбәпләрен ачыклыйбыз. Димәк, бу эшкә җитди игътибар бирергә кирәк. Бездә дуңгызларның баш санын 2000гә җиткерү һәм тармакны табышлы итү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Майга кадәр җәйге лагерьны төзеп бетерергә кирәк.

Язгы чәчүгә керешеп киләбез. Булган техника ремонтланды, яңаларны да сатып алдык, орлык бар, ашлама җитәрлек. Җәй көне ябык ындыр табагы корырга, механика мастерскойларына бара торган юлларны төзәтергә, барлык терлекчелек каралтыларын ремонтларга, газ һәм су белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл кылырга ниятлибез.

Реформалауга килгәндә, майда гомуми җыелышта барлык үзара мөнәсәбәтләрне дә көйләячәкбез.

Безнең максат - ярдәмче хуҗалыктагы һәркемнең үзен җир хуҗасы дип санавына, хуҗалыкның рентабельлелегенә һәм бурычларыбызны түләп бетерүгә ирешү.

**Р.Хәмзин,**
**«Алга» КХАсы рәисе:**

### Ахыр нәтиҗәгә бәйләп

Бездә барлыгы 5 кооператив төзелде. Аларның дүртесе ит, сөт, йон җитештерү, шикәр чөгендере, ашлык һәм терлек азыгы үстерү белән шөгыльләнәчәк, бишенчесе - хезмәт күрсәтүче кооператив.

Хуҗалыкның 6025 гектар җире бар, шуның 5 мең гектары чамасы - сөрү җире. Бер кешегә 5,6 гектар җир пае туры килә. 566 кешегә җир паена ия булуы турында таныклык тапшырдык.

Кооперативлар белән килешүләр, шулай ук биналар, корылмалар, транспортны һәм башка төп фондларны бүлеп аларга тапшыру турында актлар төзелде. Җитештергән продукцияләрен кооперативлар эшкәртү предприятиеләренә дә үзләре үк урнаштырачаклар. Бушаган вакытларында алар хуҗалыкта билгеләнгән хакка башка кооперативларга, кооператив составындагы пенсионерларга да хезмәт итә алалар. Хуҗалыкта барлык үзара исәп - хисап ясау расценкалары билгеләнде, ә ягулык, чәчүлек орлык һәм башка материаллар аларны кайтарту чыгымнарын да исәпкә алып биреләчәк. Кооператив членнары хезмәтенә ахыр нәтиҗәләрдән чыгып түләнәчәк, ә ел ахырында йомгак ясаганда барлык чыгымнар да, урнаштырылган продукция күләме дә, аны сатудан кергән саф табыш та исәпкә алыначак.

**Ә.Гарифуллин,**
**«Әлмәт» КХАсы рәисе:**

### Кем - эшләми, шул - ашамый

Үзгәртеп кору нәтиҗәсендә хуҗалыкта җитештерүче өч комплекслы һәм бер хезмәт күрсәтү кооперативы төзелде. Алар карамагына төп фондлар, тракторлар, авыл хуҗалыгы машиналары, терлек тапшырылды, 676 җир пае да бүлеп бирелә.

Кем - эшләми, шул - ашамый, дигән принцип хакимлек итәргә тиеш дип саныйбыз. Максат - контрольнең чек формасына нигезләнгән хуҗалык исәбенә азрак чыгым белән күбрәк продукция җитештерү.

Кызганычка каршы, хуҗалыкның финанс хәле канәгатьләнерлек түгел. 1996 ел өчен генә дә КХА членнарына 230 млн. бурычыбыз бар, ә 6 айга бирәчәгебез - 431 млн. сум. Ә бит кооперативлардагы хуҗалык исәбенең нигезендә ай саен авanслау ята.

Промышленность товарларына һәм авыл хуҗалыгы продукциясенә бәяләр арасындагы аерма һаман да зур булып калса, безгә акчаны көтәсе дә юк - җитештергән продукциябез өчен тиясе бар средство төрле салымнарны капларга тотып калына.

Кыенлыкларга да карамастан, без үз бурычларыбызны беләбез һәм аларны үтәячәкбез. Кооперативларда эш чыгымнарны исәпләп алып барылырга тиеш. Төгәл учеттан башка алга китеш юк. Кешеләребез, банкта аерым счетлар ачып тормыйча, күмәкләп эшлиләр.

Хәзер - чәчү вакыты. Барлык кооперативларда да җитәрлек кадәр орлык, ашлама бар, булган техника ремонтланган. Көздән туңга сөреп бетереп калдырган идек һәм хуҗалык эшчәннәре язгы кыр эшләрен оешкан төстә үткәреп, үз алларына куйган бурычларны эшкә ашырырга ниятлиләр.

## Иртәгә - Пасха

**Пасха - барлык христиан бәйрәмнәре арасында да иң олысы, сөенечле һәм шатлыклысы.**

**Христосның Яңадан тууы, җирдә кырык көн торганнан соң күккә ашуына кагылышлы бу бәйрәм кырык көн буе бәйрәм ителә.**

**Ул чордагы атналарның һәрберсенең аерым исеме бар. Әйтик, Фома атнасы дип йөртелгән беренче атнаның сишәмбесе, ягъни Пасхадан соңгы тугызынчы көн халыкта Радуница диеп йөртелә. Бу көн турында халык мәкалендә: «Радуницада иртән сөрәләр, көндез елыйлар, кичен сикерешәләр» диелә. Бу Пасхадан соң чынлап торып кыр эшләренә керешелә, Радуницада зиратка барыла (Родители), ә кичен күңел ачалар дигәнне аңлата.**



**Изге бәйрәм белән!**

Уңганлык тиз күренә



Екатерина Васильевна Ефимова турында уңган, булган, диләр Елаурда. Фермада күптән түгел генә эшли башласа да, Екатерина Васильевна хуҗалыкның алдынгы савучылары исемлегенә керде. Хәзер аның карамагындагы һәр баш мал тәүлек саен уртача 12 килограмм сөт бирә.

**Рәсемдә: МСОның «Төзүче» ярдәмче хуҗалыгы сыер савучысы Е.Ефимова.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

Мәгариф маяклары

## ҮЗЕ - ИЗГЕЛЕК ӨЛГЕСЕ

Аның беренче дәресе әле дә хәтердә. Яңа Әлмәт урта мәктәбенең агач янкормасындагы без укый торган кысан, шыксыз бүлмә ул кергәч киңәеп, яктырып киткәндәй булган иде. Зәңгәр тышлы журналны өстәлгә җәеп салды да исемлек буенча фамилияләребезне укып китте ул. Чамалы гына тулы гәүдәле, диңгез дулкынысдай зәңгәр зур күзле немец теле укытучыбыз шул минутта ук безнең күңелләребезне яулап алды. Аның дәреската керүен көтеп ала торган булдык. Без бәхетле идек: авыл мәктәбендә татар телен укый алмасак алмадык, әмма алты ел дәвамында чит телне азмы - күпмедер дәрәҗәдә үзләштердек. Һәрхәлдә, мәктәптән соң укуларын дәвам иттерүчеләребез немец теле буенча һичкайчан авыр «хәлдә» калмадылар. Моның өчен без укытучыбыз Татьяна Геннадьевнага бурычлы идек.

Ул вакыттан соң ике дистә елга якын гомер үтте. Укытучыбыз өчен укучылар булган нәниләр үзләре өлкән кешеләр булып, төрле һөнәрләр үзләштерделәр. Ә Татьяна Геннадьевна безнең өчен һаман да укытучы. Хәзер инде тел серләренә генә түгел, ә тормышка өйрәтүчебез, киңәш бирүчебез дә. Хәер, чын мәгънәдә укытучы булган кеше башкача булмыйдыр да инде. Бөтен гомере укытучылар, укытучылык белән бәйле бит аның. Мәктәп, дәрес, укучы дигән сүзләрне дә ул теле ачылганда ук әйтә башлагандыр, мөгаен. Әтисе Геннадий Александрович белән әнисе Клавдия Александровна Дудкиннар икесе дә укытучылар иде бит. Рогозино авылында гына түгел, Мамадыш районы күләмендә танылган педагоглар иде алар. Гаиләдәге өч балага да яхшы итеп тәрбия биреп, югары белемле итүләре дә очраклы түгел шул. Таңяны Алабуга пединститутының чит телләр факультетын тәмамлагач, юллама буенча Октябрь районына җибәрделәр. Яңа Әлмәт мәктәбенә килеп эшли башлавының беренче елларында ук укытучы кыз танылган укытучылар Прокопьевлар килене дә булды. Кайнанасы Ирина Павловна башлангыч мәктәптә мөдир, Василий Павлович урта мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыта иде. Каен сеңелләре Луиза белән Валентина да, ире Валерий да укытучылар. Берзаман Прокопьевлардан алты кеше эшли иде коллективта. Иң мөһиме, барысы да көчле укытучылардан саналдылар.



1977 нче елда мәгариф бүлеге Валерий Васильевичны Чулпан авылы мәктәбенә директор итеп җибәргәч, кече Прокопьевларга гаиләләре белән Әлмәттән күчеп китәргә туры килде. Бу вакытта аларның нәкъ әнисенекедәй зур зәңгәр күзле Светалары, тач әтисе кебек Игорьлары бар иде.

Ипле холыклы, аралашучан Прокопьевлар Чулпанда да тиз арада үз кешегә әйләнделәр. Әйтерсең лә гомер буе шунда яшәгәннәр. Татьяна Геннадьевна биредә дә немец теле укытты. Мәктәп аның өчен икенче йортка әверелде. Көндез дәрес бирде, аннан соң түгәрәкләр үткәрергә кала торган иде. Балаларны макраме үрергә, челтәрләп бәйләргә, табигый материалдан төрле әйберләр ясарга, тортлар пешерергә, яшелчә тозларга өйрәтүче дә ул булды. Гөлләргә мәхәббәтен балаларга да күчерә алды. Гомер - гомергә чит телләр кабинеты үзенчәлекле оранжереяны хәтерләтте. Прокопьевлар өендә дә затлы җиһазларга караганда гөлләрне, үз куллары белән ясаган әйберләрне өстен күрделәр. Һәм бу бүгенгәчә шулай.

Татьяна Геннадьевна җәйге каникулда рәхәтләнеп ял итүнең ни икәнен белми. Чөгендер дә эшкәртә, ихтыяҗ туганда басудагылар өчен аш та пешерә, башка эшкә дә чыга. Мәктәптә генә түгел, авыл күләмендә оештырылган чараларда да башлап йөри ул. Ә инде укытучы буларак һөнәри осталыгы турында язып та, сөйләп тә бетерерлек түгел. 1990 нчы елда «РСФСРның атказанган укытучысы» исеменә лаек булуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Т.Прокопьеваның районда әйдәп баручы укытучы квалификация категориясенә ия бердәнбер чит теле укытучысы булу да аңлатма таләп итми. Егерме сигез ел буена бөрөзлексез мәктәптә эшләп туплаган тәҗрибәсе, профессиональ осталыгы турында сөйли ул.

Прокопьевлар бик матур яшәделәр авылда. Өйләреннән һичкайчан кеше өзелмәде: ярдәм сорап та, киңәшләшергә дип килүчеләр дә бик күп иде араларында. Татарлар белән татар телендә аралаштылар. Шуңа да күптән түгел вафат булган Валерий Васильевичны җирләгәндә гаиләнең чиксез авыр хәсрәтен уртаклашырга дип татарлар да, руслар да, чувашлар да килделәр. Авыр минутларда аларның барысы да Татьяна Геннадьевна өчен зур терәк булдылар. Хәер, үзе халык өчен кече күңеллелек, изгелек өлгесе булып балаларның гына түгел, бөтен авыл халкының кайгысын да, шатлыгын да уртаклашып яшәгән кешегә карата шундый мөнәсәбәт табигый хөрмәт, ихтирам билгесе инде ул.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: РСФСРның атказанган укытучысы Т.Г.ПРОКОПЬЕВА дәрес вакытында.**

# Ихтирамлы, игътибарлы

Фәния Бариевна Нәбиуллинаның Алабуга педагогия институтын тәмамлап кайтып туган авылы Чулпан урта мәктәбендә эшли башлавына 13 ел үтеп киткән. Математика һәм химия фәннәреннән укыта. Хезмәтен ярата Фәния Бариевна, күңелендә балаларга карата җылылык, ихтирам хисе сүнми, киресенчә, ныгый бара.

Аның эшчәнлеге хакында балаларның белеме генә түгел, тәҗрибә уртаклашу буенча дәресләргә килгән коллегаларының уңай бәяләмәләре дә ачык сөйли.

**Рәсемдә: Фәния Нәбиуллина.**

Н.АЗИЗОВ фотосы.



## Укымый калмагыз! Укымый калмагыз!

# ВӘХШИЛЕК

## 1996 елның 14 декабрендә районда дүрт кеше үтерелде

***Андый җинаятьләр турында язу авыр - бердән, кемнеңдер җан җәрәхәтен кузгатудан куркасың, икенчедән, уйламый - нитмичәрәк язып тапшлап зур хата эшләмәгәем дип тә шикләнәсең-әле суд процессы алда бит. Әмма шундый характердагы материал белән танышып, җинаятнең никадәр салкын кан һәм бәгырьсезлек белән башкарылганлыгын күргәч йөрәк түзми. Бу гамәлләрнең явызлыгы, шәхеснең таркалуы, мораль кыйммәтләрнең юкка чыгуы турында һәркем белергә һәм аннан сакланырга тиеш дип уйлыйсың.***

Быел 8 апрельдә Норлат шикәр заводы эшчеләренең дача участоклары бәрәңге кырында Норлат - Чаллы Башы юлыннан 900 метрлап эчтәрәк Шәрипов мәете табылды (бу һәм башка фамилияләр үзгәртелде). Ул утлы коралдан күкрәгенә атып үтерелгән була. Узган елның 14 декабрендә ул кичке сәгать 5 ләр тирәсендә эшеннән чыгып китә, әмма өенә кайтып керми, «хәбәрсез югалган» дип аны эзләү игълан ителә. Шул көнне кич белән, соңрак ачылганча, Норлатта Бажановлар гаиләсеннән өч кешене - ир белән хатынны һәм кызларын үтереп чыгалар. Болар арасында эчке бәйләнеш барлыгын тоеп, тикшерүчеләр үзләре алдан уйлаган фаразга кайталар. Һәм ул дөрес тә булып чыга.

Советская урамындагы йортларның берсендәге 14нче фатирдагылар өчен ул көн гадәттәгечә башланды. Кичке чәйне ашыкмыйча гына гадәттәгедән иртәрәк эчтеләр. Өстәл артында сүз дә гадәттәгечә ипле ага: кызлары Валентина, Украинадагы фатирын сатып, картлар янына кайтты. Бажановлар ничәнче кат инде кызларына биредән, Норлаттан йорт алу турында сүз кузгаттылар, ә Валя һаман оныгы белән аерылышуга күнә алмыйча аптырады. Берсе дә бу сәгатьләрнең алар гомеренең соңгы сәгатьләре булырын уена да китереп карамый. Шуңа күрә шаку белән ишекне дә бер шиксез барып ачалар. Бусагада таныш булмаган ир - ат аларга фатир тәкъдим итеп килгәнлеген әйтә. «Визит»ны оештыручы, элек хөкемгә тартылган Галимов үзе тышта кала, ә икесе - башларына кара оек кигән, ау мылтыгы һәм баулар алып килгән Шәрипов белән Могыйнов фатирга бәреп керәләр. Өйдәгеләрне бәйләп идәнгә егып салалар. Хуҗаларның җыеп куйган акчаларын тапмакчы булып тиз - тиз генә бөтен фатирны актарып чыгалар. Өчесенә дә акча бик тә кирәк була шул: Шәриповның декабрь ахырында туе буласы, Мостафинга аварияга очраган машинасын рәткә кертергә кирәк була. Тик менә акча дигәнне генә таба алмыйлар - Валяның әтисе, элеккеге банк хезмәткәре, кызына акчасын банкка салырга киңәш иткән була - ышанычлырак та, проценты да арта тора. Ачуларыннан шартларга җиткән теге бәндәләр йортның астын - өскә китерәләр, кулларына туры килгән бар нәрсәне аударып - ватып бетерәләр. Йорттагыларны кансыз рәвештә үтерәләр дә, кладовкадагы аракыларын алып чыгып китәләр. Өстәл өстендә ерткалап бетерелгән саклык кенәгәсе белән гаилә башлыгының көндәлеге кала. Иван Семенович һәр көнне өстәл календарен ачып, бүген нинди һава торышы булуын язып бара торган була. Соңгы язма - 1996 елның 14 декабре битендә...

Ул арада җинаятьчеләр Шәриповның туган авылы Югары Норлатка юл тоталар. Юлда әйткәләшеп китеп, Могыйнов «кулдашын» атып үтерә. Икенче көнне Галимов белән икәүләп аның мәетен карга күмеп куя. Аягыннан Галимовныкы булган ботинкаларны салдырып алалар. Үтерелгән хатыннарның берсе биргән акчаны алар ашыгычлык белән тапмыйлар, Шәрипов кесәсендәге ул миллион сумга соңыннан милиция хезмәткәрләре тап була.

Үтерүчеләр мәетне яндырырга да уйлаган булалар. Тик бу ниятләрен гамәлгә ашырырга өлгерә алмый калалар. Һәм менә ни өчен... Һаман да шул акча юнәтү нияте белән Могыйнов, бу юлы инде Яңа Иглайдан 18 яшьлек Сәфәров белән бергә, газ пистолеты белән коралланып, 20 гыйнварда Югары Норлатта берәүнең өенә бәреп керәләр. Ул кеше машинасын саткан дигән сүз йөри һәм болар аңардан акча таләп итәләр. Әмма бу хуҗа каушап калмый һәм җинаятьчеләрнең кирәкләрен бирә. Тегеләр, Галимовның өендә өсләрен алыштыралар да (бу юлы да котыртучы ул була), өчәүләп юкка чыгалар: Галимов кача, ә икесен икенче көнне Чаллы Башында тоталар. Октябрь район суды талау нияте белән һөҗүм итүләре өчен Могыйновны 6 елга, ә Сәфәровны 4 елга ирекләреннән мәхрүм итә һәм икесен дә Бөгелмәгә тикшерү изоляторына озаталар...

Озакламый, 8 апрельдән соң Могыйновны ашыгыч рәвештә этап белән Норлатка озаталар. Тикшерү төркеме көне - төне киеренке эшли. Бер - бер артлы сорау алулар, шаһитлар күрсәтмәләрен тыңлаулар, үтерү урынын, дәлил булган әйберләрне карау....Оператив - тикшерү чараларының бу этабы уңышлы тәмамланган: Могыйнов үзенең гаебен тулысынча таныган. Шулай итеп, җинаятьчеләр ачыкланган һәм кылган җинаятьләре өчен тиешле җәзаны алачаклар.

Соңгы ноктаны суд куячак. Тик менә нинди җөмлә ахырында булыр ул?

**Т.НАЗАРОВА.**

Җавап көтәбез

## Үги бала хәлендә

Редакцияме бу? Балалары Синдряков урамындагы «Башаккай» балалар бакчасына йөрүче ата - аналар шалтырата әле сезгә. Балалар үзеңнеке һәм үги булган төсле, юллар да шулай аерыла микәнни соң? Элек бу урамда менә дигән асфальт иде, әмма еллар үтү белән бу урам турында оныттылар. Хәзер урамның шушы бакча турысындагы өлеше бөтенләй ташландык хәлдә, асфальты тракторлар һәм зур йөк машиналары белән ваттырып бетерелгән. Шуңа күрә яз - көз моннан резин итексез үтәрмен димәдә. Былтыр Тельман урамын һәм Синдряков урамының үзәккә якын өлешен ремонтлаганда бу тирәне дә рәткә кертергә оныттылар, хәтта бер көрәк вак таш та салмадылар.

Шушы хакта газетага языгыз әле, безнең балалар кайчанга кадәр чокыр - чакырлы урамнан йөреп азапланырлар икән? Их, бакчалары түрәләрнең гүрнәчәйләре тирәсендә булса иде дә бит...


## БЕЛДЕРҮЛӘР

### Сатабыз

**Яңа «Урал» мотоциклы. Кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 18 - 24.

***

**1988 елгы, әйбәт хәлдәге «Москвич - 412 И 3».** Адрес: Ст. Разин ур., 9.

***

**Телевышка тирәсендә капиталь гараж.**

***

**Шәһәр уртасындагы 2 катлы йортның 2 нче катында, гомуми мәйданы 43 кв. метрлы 2 бүлмәле фатир.** Самарада тел.: 59 - 07 - 90.

***

**Азык - төлек комбинаты янында гараж.** Тел.: 2 - 28 - 82.

***

**3500 сумнан 20 х 20 х 40 см.лы керамзит блоклар, геркулес - 500 граммлы 2850 сум.** Яр Чаллыда тел.: 46 - 21 - 86, 46 - 51 - 00.

***

**Дача**. Адрес: К.Маркс проспекты, 1 - 16.

***

**Кутузов урамында газ китереп җиткерелгән, 21 нче йорт, кыйммәт түгел, 15 сутый бакчасы бар.** Адрес: Энгельс ур., 16 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**Әфган поселогында материаллары белән участок һәм чистарту корылмалары ягында дача участогы.** Тел.: 5 - 19 - 22.

***

**Чистарту корылмалары янында базы белән гараж.** Әфган поселогында Ситдыйковка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Некрасовка поселогында вагончыгы белән участок.** Адрес: Гагарин ур., 14 - 24.

***

**1 бүлмәле фатир.** Адрес: К.Маркс ур., 4 - 20.

***

**Рус Мәнҗесе авылында 5 сутыйлы дача участогы (вагончыгы бар).** Норлатта адрес: Совет ур., 2 - 2 (кичке 5 тән соң).

### Сатабыз яки алмаштырабыз

**Пушкин поселогында нигезе салынган участок һәм 1995 елгы ВАЗ - 21099 сатыла яки фатирга алмаштырыла.** Тел.: 2 - 11 - 34.

***

**1982 елгы ВАЗ - 2103 (12,5 млн.), 1988 елгы «Днепр» (2,5 млн.) яки - мотоблокка** тел.: 5 - 20 - 48.

### Алмаштырабыз

**Агач йортны (12 сутый җире, мунчасы, коесы, базы, каралтысы бар) - 3 бүлмәле фатирга.** Тел: 2 - 27 - 52, 2 - 19 - 37.

### Сатып алам

**Бер бүлмәле фатир сатып алам.** Арадашчының тел.: (шикәр заводы коммутаторы аша) 5 - 27 (иртәнге 8дән кичке 6га кадәр).

### Бакчачылар!

**Некрасовкадагы «Нефтяник» бакчачылык ширкәте членнарын документлар алу өчен көндезге 2дән 5кә кадәр УТТның кадрлар бүлегенә килергә чакырабыз. Үзегез белән паспорт һәм акча булсын.**

### Документлар югалды

**Валерий Георгиевич Панков исеменә бирелгән АЕ сер. № 653743 номерлы тракторчы - машинист таныклыгын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

### Эшкә чакырабыз

**НГДУ технологик - транспорт идарәсенә (УТТ) экскаваторга, торба салгычка, автокранга, КРАЗ базасындагы күтәрткеч кранга, бульдозерларга машинистлар, Д һәм Е категорияле шоферлар кирәк.**



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә.